**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 елның 30 декабрь** **№ 242**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы, вазыйфаи затлары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү турында» гы 2018 елның 16 апрелендә кабул ителгән 133 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 137 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 143 номерлы, 2018 елның 12 ноябрендәге 163 номерлы карарларынигезендә кертелгән үзгәрешләр белән )**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 16 апрелендәге 133нче номерлы “Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә органнарының сайланулы, вазыйфаи затлары, Контроль-хисап палатасы Рәисе, Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында”гы карарына (Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 137 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 143 номерлы, 2018 елның 12 ноябрендәге 163 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы 8 абзацына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Муниципаль берәмлек башлыгына, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарына еллык түләүле отпуск биргәндә, Контроль-хисап палатасы рәисенә бер айга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме түләнә. Еллык түләүле отпуск бирелгәндә бер тапкыр бирелә торган түләү гариза нигезендә башкарыла. Әгәр муниципаль хезмәтнең беренче елында календарь ел дәвамында еллык отпуск бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә. Эшләнгән вакыт муниципаль вазыйфаны биләгән көннән алып агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.».

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларны әлеге карарның 1 пунктына туры китерергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе Н. А. Вазыйхов**